ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2018 елның 19 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Инвалидлар һәм социаль яклауга аеруча мохтаҗ гражданнар өчен эш урыннары квоталау һәм резервлау турында» 2006 елның 24 июлендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 7; 2014, № 6 (II өлеш), № 12 (II өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«пенсия алды яшендәге (картлык буенча, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган иминият пенсиясен алу хокукы бирә торган яшькә кадәр биш ел дәвамында) гражданнар;».

**2 статья**

Әлеге Закон 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2018 ел, 20 декабрь
№ 104-ТРЗ